Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы

# БОЕРЫК

Казан ш.

2012 елның 17.07 121/2-пр. номерлы

“2012-2014 елларга Татарстан Республикасында эшли башлаучы фермерларга булышу” ведомство программасында катнашу очен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу буенча конкурс турында

“Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 28 февралендәге 166 номерлы карарын тормышка ашыру турында” 2012 елның 22 мартындагы 197 номерлы Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы боерыгын үтәү һәм “Крестьян (фермер) хуҗалыгын тозү һәм үстерүгә грантлар һәм эшли башлаучы фермерга көнкүреш кирәк-яраклары алу өчен бер тапкыр ярдәм бирү буенча чараларны башкарганда килеп туган Россия Федерациясе субъектының чыгым йөкләмәләрен финанслау максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр бирү турында” 2012 елның 16 маендагы 997/10 номерлы килешү нигезендә

**боерам:**

1. “2012-2014 елларга Татарстан Республикасында эшли башлаучы фермерларга булышу” ведомство программасын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Крестьян (фермер) хуҗалыкларын үстерүгә грантлар һәм эшли башлаучы фермерларны көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә бер тапкыр ярдәм бирү турында нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. КФХ төзүгә грантлар һәм көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә бер тапкыр ярдәм бирү буенча эшли башлаучы фермерларның гаризаларын карап тикшерү буенча конкурс комиссиясе составын 3 нче кушымта нигезендә расларга.

4. 2012 елның 17 июленнән 2012 елда “2012-2014 елларга Татарстан Республикасында эшли башлаучы фермерларга булышу” ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу буенча конкурс үткәрү хакында 4 нче кушымта нигезендә белдерү бастырырга

5. Крестьян (фермер) хуҗалыгын үстерүгә грантлар һәм көнкүреш кирәк-яраклары алу өчен бер тапкыр ярдәм бирү буенча гаризалар сайлап алу буенча конкурс комиссиясе каршындагы Эксперт советын 5 нче кушымта нигезендә төзергә һәм расларга.

6. Муниципаль районнарда авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек Идарәләре

җитәкчеләренә “2012-2014 елларга Татарстан Республикасында эшли башлаучы фермерларга булышу” программасы буенча халыкны мәгълүмат белән тәэмин итәргә ярдәм итәргә.

7. Предприятиеләрнең структурасын үзгәртү һәм агробизнесны үстерү бүлеге җитәкчесе А.Н. Молокинга оештырырга:

7.1. Конкурс үткәрү, кирәкле документлар һәм конкурс белән бәйле бүтән мәгълүмат турында белдерүне Министрлыкның http://agro.tatarstan.ru/ рәсми сайтында “Мәгълүмат-консультаци хезмәте” һәм “Планнар, программалар һәм конкурслар” бүлекләрендә, шулай ук “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә баш биттә баннер урнаштырырга.

7.2. Конкурс комиссиясе сәркатибе тарафыннан гаризалар һәм документлар кабул итү, конкурс комиссиясе каршындагы эксперт советы тарафыннан аларга беренчел экспертиза ясау һәм 2 нче кушымта нигезендә Крестьян (фермер) хуҗалыкларын төзүгә һәм үстерүгә грантлар һәм эшли башлаучы фермерларны көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә бер тапкыр ярдәм бирү турында нигезләмәдә каралган тәртиптә һәм срокларда конкурс комиссиясенә тапшыру.

7.3. Мәгълүмат җыю, эшкәртү һәм “2012-2014 елларга Татарстан Республикасында эшли башлаучы фермерларга булышу” ведомство программасын тормышка ашыруны контрольдә тоту.

8. Финанслау бүлеге җитәкчесе А.Х. Гельманга 2 нче кушымта нигезендә Крестьян (фермер) хуҗалыкларын төзүгә һәм үстерүгә грантлар һәм эшли башлаучы фермерларны конкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә бер тапкыр ярдәм бирү турында нигезләмәдә каралган билгеләнгән лимитлар кысаларында акча чараларын ү вакытында илтеп җиткерүне тәшкил итү.

9. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г.Әхмәтов

ТР АХhАТМ боерыгына
1 нче кушымта

**“2012-2014 елларга Татарстан Республикасында эшли башлаучы фермерларга булышу” ведомство программасы**

Эчтәлек


1 бүлек Программа хәл итүгә юнәлдерелгән мәсьәләләрнең сыйфатламасы 4

2 бүлек Программаның максаты һәм бурычлары 6

3 бүлек Тормышка ашыруның нәтиҗәләреһәм максат индикаторлары 6

4 бүлек Программа чаралары исемлеге һәм тасвирламасы 8

5 бүлек Программаны тормышка ашыру сроклары 12

6 бүлек Программаны тормышка ашыруның соңиаль һәм икътисадый нәтиҗәләре тасвирламасы 12

7 бүлек Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү һәм мониторингы 13

8 бүлек Кирәкле ресурсларның зарурлыгын исәпләү 14

9 бүлек Программаны тормышка ашыру белән идарә итү системасы 14

1 нче кушымта 15

2 нче кушымта 16

# ПАСПОРТ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | “2012-2014 елларга Татарстан Республикасында эшли башлаучы фермерларга булышу” ведомство программасы (алга таба – Программа) |
| Норматив акт исеме һәм номеры | “Эшли башлаучы фермерларга булышуга федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлеп бирү кагыйдәләрен раслау турында” 28.02. 2012 елдагы 166 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары; 23.04. 2012 елдагы 613 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары |
| Дәүләт заказчысы – Программаның координаторы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Программаның төп әзерләүчеләре | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Программаның максаты һәм бурычы | Максат:<br>Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыкларын үстерүне стимуллаштыру.<br>Бурыч:<br>эшли башлаучы КФХ һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару белән шөгыльләнүче гражданнарның җитештерү базасын киңәйтү һәм яңарту өчен шартлар тудыру |
| Программа чараларының сыйфатламасы | Бурычларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән чаралар комплексы түбәндәге юнәлешләрне үз эченә ала:<br>1. крестьян (фермер) хуҗалыкларын үстерүгә грантлар бирү;<br>2. эшли башлаучы фермерларны көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә бер тапкыр ярдәм күрсәтү; |
| Прогорамманы тормышка ашыру сроклары | 2012 – 2014 еллар |

| | |
|---|---|
| Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | 2012-2014 елларга Программаны финанслауның гомуми күләме 607.546 млн. сум тәшкил итә:<br>Шлу исәптән еллар буенча: 2012 ел- 155,171 млн. сум;<br>2013 ел - 221,375 млн. сум ;<br>2014 ел - 231,000млн. сум ;<br>Федераль бюджеттан финанслау, барлыгы -231,923 млн. сум, алардан:<br>2012 ел - 59,193 млн. сум ; |
| | 2013 ел - 84,530 млн. сум;<br>2014 ел - 88,200 млн. сум;<br>Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслау -320,392 млн. сум, алардан:<br>2012 ел - 81,872 млн. сум;<br>2013 ел - 116,72 млн. сум;<br>2014 ел - 121,80 млн. сум<br>Җәлеп ителгән чаралар, барлыгы - 55,231 млн. сум, алардан:<br>2012 ел - 14,106 млн. сум;<br>2013 ел -20,125 млн. сум;<br>2014 ел - 21,000 млн. сум; |
| Программа чараларын тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре һәм социаль-икътисадый нәтиҗәлелек күрсәткечләре | Максат индикаторы:<br>2011 ел дәрәҗәсенә карата хуҗалык итүче крестьян (фермер) хуҗалыкларының саны арту -1,17<br>Дәүләт ярдәме белән үзләренең крестьян (фермер) хуҗалыкларын үстерү проектларын тормышка ашырган крестьян (фермер) хуҗалыклары саны - 329,<br>шул исәптән:<br>2012 елда - 94 берәмлек;<br>2013 елда- 115 берәмлек;<br>2014 елда- 120 берәмлек;<br>булдырылган эш урыннары саны – 990 дән дә ким |

## Программаның төп төшенчәләре

**Гариза бирүче** — үзен эшли башлаучы фермер итеп тану өчен конкурс комиссиясенә гариза биргән, элегрәк эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырмаган һәм гариза бирү вакытына фермер хуҗалыгы эшчәнлеген 12 айдан да артык гамәлгә ашырмаучы Россия Федерациясе гражданы.

**Эшли башлаучы фермер** – крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлау буенча конкурс комиссиясе тарафыннан конкурс сайлаулары нәтиҗәләре буенча крестьян (фермер) хуҗалыгын (алга таба –КФХ) үстерүгә грант бирүгә билгеләнгән эшли башлаучы фермерларга булышу программасы катнашучысы.

## 1 бүлек. Программа хәл итүгә юнәлдерелгән мәсьәләләр сыйфатламасы

Соңгы елларда турыдан-туры агросәнәгать комплексы оешмаларында эшләүче авыл халкы саны туктаусыз кими һәм 100 меңнән кимрәк кешене тәшкил итә. Шул рәвешчә аларны эш белән тәэмин итү, мәшгульлеген булдыру, керемнәр белән тәэмин итү мәсьәләсе килеп туа, аны хәл итүгә республикада бер-берсенә бәйле чараларның тулы ер комплексы юнәлдерелгән. Программа авыл җирлегендә яшәүчеләрнең тормыш дәрәҗәсен күтәрергә,авылда яшьләрнең эшлекле активлыгын үстерергә, авылча яшәү рәвешен саклап калуга юнәлдерелгән.

Авылда кадрлар составын ныгыту, кече бизнесны үстерү һәм яңа эш урыннары булдыру, авыл яшьләренең кызыксынуын һәм эш белән тәэмин ителешен арттыру максатларында программа белән КФХ үстерү буенчачаралар комплексы тәкъдим ителә. Эшли башлаучы КФХ җитди мәсьәләләрнең тулы бер рәте белән очрашалар: беренчел капитал җитмәве сизелдерә, закладка салырга мөлкәт җитмәү сәбәпле алар кредитлар ала алмыйлар. Соңгы елларда көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин ителеш кискен тора, бу үз чиратында өстәмә акча чаралары таләп итә. Крестьян (фермер) хуҗалыклары, финанс тотрыклылыгына җитмичә, таркалалар.

Моның белән бергә халыкның шәхси ярдәмче хуҗалыклар секторында милкендә яки куллануда икегә кадәр һәм аннан да күп гектар җире булган һәм товар продукциясе җитештерүгә юнәлдерелгән хуҗалыклар барлыкка килде. Инде хәзер үк алар продукцияләре күләме белән кайбер фермер хуҗалыкларын узып китәләр. Гамәлдә билгесез статуслы, җитештерү элемтәләре бозылган табигый крестьян хуҗалыклары барлыкка килә. Мондый хуҗалыкларның формалашуы эре коллективлы предприятиеләр таралганда аларның хуҗаларының киләчәктә гамәлдә булуларын сайлау альтернативасы булмау белән нигезләнә.

Соңгы елларда авыл хуҗалыгы предприятиеләрен үстерү тәҗрибәсе күрсәтүенчә, хуҗалык эшчәнлегендә ирешелгән нәтиҗәләр үз көчләре һәм чаралары белән генә крестьяннарның социаль проблемаларын нәтиҗәле хәл итеп һәм җитештерүне модернизацияләп булмый.

Яңа КФХ төзү шулай ук хуҗалык корылмаларын проектлауга, аларны инженер челтәрләренә тоташтыруга, лизинг түләүләре буенча беренче кертемне түләү өчен сизелерлек чыгымнар таләп итә.

Авылда хуҗалык итүнең кече рәвешләренә булышуның алып барыла торган дәүләт сәясәте кече авыл хуҗалыгы эшкуарлыгы субъектларына банкаларының субсидияләнә торган кредитларын һәм авыл хуҗалыгы кулланучылары кооперативларының заемнарын алу мөмкинлеген киңәйтә алды.

Хуҗалык итүнең кече рәвешләренә булышу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан дәүләт ярдәме күләме 2006 елдан җәлеп ителгән инвестицияләнгән һәм кыска вакытлы кредитлар һәм заемнар буенча процент ставкаларын субсидияләү рәвешендә 1 437 400 мең сум тәшкил итә.

Статистика мәгълүматлары буенча 2012 елның 1 гыйнварына КФХ гомуми саны 1866 берәмлектәшкил итә.

Үсешнең сценариясе сүлпән булган очракта фермер секторы үз үсешен алга

җибәрү өчен өстәмә чыганак таба алмый, ә ярлыланган эчке чыганаклар авыл хуҗалыгының җитештерү вазыйфасын тәэмин итә алмаячак.

## 2 бүлек. Программаның максаты һәм бурычы

Программаның максаты – Татарстан Республикасында КФХ үсешен стимуллаштыру.

Әлеге максатны тормышка ашыру һәм җитештерү балансының вә авыл хуҗалыгы продукциясен кулланунын тотрыклылыгы кысаларында дәүләт ярдәме түбәндәге юнәлешләрдә гамәлгә ашырылачак:

ит һәм сөт терлекчелеге;

атчылык, сарыкчылык һәм кәҗә үрчетү;

дуңгызчылык;

авыл хуҗалыгы кошчылыгы;

балчылык;

бөртекле һәм бортекле-кузаклы культуралар җитештерү;

бәрәңгечелек;

яшелчәчелек (ачык һәм ябык грунтта);

җимеш һәм җиләк культуралары үстерү.

Программаның бурычы – эшли башлаучы КФХ һәм шәхси ярдәмчек хуҗалыкалып бару белән шөгыльләнүче гражданнарның җитештерү базасын киңәйтү һәм яңарту өчен шартлар тудыру.

## 3 бүлек. Тормышка ашыру нәтиҗәләре һәм максат индикаторлары

**Программа чараларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр һәм социаль-икътисадый нәтиҗәлелек күрсәткечләре:**

Эшли башлаучы фермерлар дәүләт ярдәме катнашы белән үзләренең КФХ үстерү проектларын гамәлгә ашыра алачаклар.

Программа чараларын тормышка ашыру түбәндәге нәтиҗәләргә килергә мөмкинлек бирә:

1. Авыл җирлекләре территорияләрен ныклы үстерергә һәм эшкәртергә, шулай ук авыл җирлегендә гамәлдә булган урнашу системасын саклауны биргән 990 нан да ким булмаган өстәмә эш урыны булдыру;

2. КФХ үстерүгә, аны конкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә һәм авыл җирлегендә гадәти тормыш рәвешен саклауга ярдәм алу.

**Программа чараларын тормышка ашыруның максат индикаторлары булып торалар:**

дәүләт булышлыгы ярдәмендә үз хуҗалыкларын үстерү проектларын тормышка ашырган КФХ саны;

булдырылган өстәмә эш урыннары саны.

1 таблица. Максат индекаторлары

| Күрсәткечләр | 2012 г. | 2013 г. | 2014 г. | Барлыгы 2012-2014 елларда |
|---|---|---|---|---|
| Дәүләт булышлыгы ярдәмендә үз хуҗалыкларын үстерү проектларын тормышка ашырган КФХ саны | 94 | 115 | 120 | 329 |
| Булдырылган өстәмә эш урыннары саны | 285 | 345 | 360 | 990 |

Программа чараларын тормышка ашыруның нәтиҗәсе объективлык, дереслелек, үтә күренмәлелек, чагыштыру критериеләренә җавап бирә торган күләмле күрсәткечләр белән билгеләнәләр.

2 таблица. Программаның нәтиҗәсе

| Максат индикаторы | Котелә | 01.01.2012 | Индикатор мәгънәсе, | | | Макса |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2012 г. | 2013 г. | 2014 г. | |
| Фермерлар саны, | 2215 | 1886 | 1980 | 2095 | 2215 | 2014 |
| шул исәптән үз КФХ үстерү проектларын дәүләт булышлыгы ярдәмендә тормышка | 329 | Х | 94 | 115 | 120 | 2014 |

Индикатор мәгънәсе – 2011 ел дәрәҗәсенә карата хуҗалык алып баручы КФХ саны арту.

Максат индикаторын исәпләү түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$K = \frac{S}{S_Z},$$

монда:

K – максат индикаторы;

S – 01.01.2015 ел торышына хуҗалык итүче КФХ саны;

$S_Z$ – 01.01.2012 ел торышына хуҗалык итүче КФХ саны.

Программа чараларын тормышка ашыру ахырына максат индикаторы мәгънәсе түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$K = \frac{2215}{1886} = 1,17$$

## 4 бүлек. Программа чаралары исемлеге һәм тормышка ашыру механизмы

4.1. Эшли башлаучы КФХ башлыкларына КФХ үстерү өчен грантлар бирү һәм көнкүреш кирәк-яраклары өчен бер тапкыр ярдәм күрсәтү Программаның төп чаралары булып торалар.

Эшли башлаучы фермерларны үстерүгә ярдәм күрсәтү өчен КФХ башлыклары, зарур булганда, торак шартларын яхшырту буенча программаларга кертеләләр.

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы республика гаризасы һәм төзелгән Килешүләр нигезендә Дәүләт программасы кысаларында һәм шартларында Программа чараларын бергәләп финаслауда катнаша. Бергәләп финанслау "Эшли башлаучы фермерларга булышу өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләрне бүлеп бирү һәм тарату кагыйдәләрен раслау турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 28 февралендәге 166 номерлы карары белән расланган Эшли башлаучы фермерларга булышу өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләрне бүлеп бирү һәм тарату кагыйдәләрендә билгеләнгән шартлар нигезендә һәм лимитлар кысаларында гамәлгә ашырыла.

4.2. Эшли башлаучы фермерларны сайлап алу буенча конкурс үткәрү тәртибен һәм гариза бирүчеләрне эшли башлаучы фермерларга булышу буенча ведомство программасы составына кертү турында карар кабул итү тәртибен үз эченә алган крестьян (фермер) хуҗалыкларын төзүгә һәм үстерүгә грантлар бирү һәм эшли башлаучы фермерларга көнкүреш кирәк-яраклары өчен бер тапкыр ярдәм күрсәтү турында нигезләмә, Крестьян (фермер) хуҗалыкларын үстерүгә грантлар бирү һәм эшли башлаучы фермерларга көнкүреш кирәк-яраклары өчен бер тапкыр ярдәм күрсәтү өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу буенча ведомствоара конкурс комиссиясе турында нигезләмә һәм аның составы Министрлык тарафыннан раслана. Министрлык Программа катнашучыларын сайлап алуга конкурс игълан итә, аны үткәрү тәртибен һәм вакытын билгели.

Конкурс комиссиясе составына республиканың дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләре (комиссия составының яртысыннан артык түгел), агросәнәгать комплексы тармагында эшчәнлек алып баручы юридик һәм физик затлар кертелә. Конкурс комиссиясе составына кредит, фәнни, белем бирү, юридик, консультация, консалтинг, аудит, ревизия һәм җәмәгатьчелек оешмалары, фермерлар ассоциацияләре вәкилләре кертелергә мөмкин.

Конкур комиссиясе гариза бирүчеләрнең гаризаларын (алга таба - гариза) һәм аларга документларны Министрлык боерыгы белән билгеләнгән срокларда карап тикшерә, гариза бирүче белән кара-каршы әңгәмә үткәрә, Программада катнашучылар составына кертә, КФХ үстерүгә грант һәм (яки) эшли башлаучы фермерларга көнкүреш кирәк-яраклары өчен бер тапкыр ярдәм суммасын билгели.

Конкурска документларын тапшырганда гариза бирүче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган форма буенча Гариза һәм теркәлә торган документларның исемлеген ике нөсхәдә төзи, һәр як өчен бер нөсхә.

Конкурс комиссиясе гариза бирүчеләрне Программа катнашучылары

составына кертү турында карар кабул иткәндә гариза бирүче документларында күрсәтелгән мәгълүмат белән бергә түбәндәгеләрне исәпкә ала:

гариза бирүченең яшәү шартларын һәм КФХ урнашу урыны буенча аның көнкүреше уңайлыкларының югары дәрәҗәсен;

КФХның эре торак пунктлардан ераклыгын;

җитештерелә торган авыл хуҗалыгы продукциясен сатуның үз каналлары булуын;

авыл хуҗалыгы кулланучылары кооперативларында әгъзалыкны;

крестьян (фермер) хуҗалыгын төзүгә сорала торган грантның кечкенәрәк күләме;

җирле халык өчен эш урыннары бирелүен;

социаль һәм бюджет җаваплылыгын;

җитештерү фондлары булуны;

нәселле авыл хуҗалыгы терлеге булуны;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр булуын;

эшчәнлек репутациясен һәм кредит тарихын;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарыннан, физик затлардан, җәмәгатьчелек оешмаларыннан, йөкләүчеләрдән тәкъдимнәрне һәм мөрәҗәгатьләрне,

кара-каршы әңгәмә нәтиҗәләрен.

Конкурс комиссиясе эшли башлаучы фермерга бер үк вакытта крестьян (фермер) хуҗалын төзү өчен грант һәм көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итү очен бер тапкыр ярдәмне бирү, шул ук вакытта аларның берсен генә бирү турында карар кабул итә ала.

Эшли башлаучы фермерга ведомство Программасында катнашуы турында 1 нче кушымтага яраклы рәвештә, яклау дизайны һәм билгесе булган сертификат бирелә.

4.3. КФХ үстерүгә грант - эшли башлаучы фермерның Татарстан Республикасы авыл җирлекләре территориясендә КФХ төзү һәм үстерү максатларында Дәүләт программасы нигезендә дәүләт булышуының бүтән юнәлешләре кысаларында кайтарылмаган чыгымнарын бергәләп финанслау өчен кредит оешмасында ачылган счетына Министрлык тарафыннан күчерелә торган бюджет чаралары.

Крестьян (фермер) хуҗалын үстерүгә грантның иң зур күләме Министрлык боерыгы белән раслана.

Эшли башлаучы фермерга бирелә торган КФХ үстерүгә грантның суммасы эшли башлаучы фермерның үз акчалары барлыгын исәпкә алып, конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Грант суммасы эшли башлаучы фермерның чыгымнары планына төгәл туры килергә тиеш. Эшли башлаучы фермер тарафыннан чыгымнар планын үзгәртү, шул исәптән бирелгән грант кысаларында, конкурс комиссиясе белән килештерелергә тиеш.

КФХ үстерүгә грант эшли башлаучы фермер счета килгәннән соң 12 ай эчендә чыгымнар планында күрсәтелгән максатларга тотылырга тиеш.

Чыгымнар планына Татарстан Республикасы территориясендә КФХ үстерергә юнәлдерелгән һәм түбәндәге максатларга туры килә торган исемнәр

(статьялар) кисемендәге чыгымнар керә:

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлекләре сатып алу

авыл хуҗалыгы терлекләрен тоту, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәк булган җитештерү һәм саклау биналарын, урыннарын төзү (реконструкцияләү) өчен проект документларын эшләү;

авыл хуҗалыгы терлекләрен тоту, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәк булган җитештерү һәм саклау биналарын, урыннарын, өстәмә корылмаларны, инженер челтәрләрен, киртәләрне һәм төзелмәләрне сатып алу, төзү, ремонтлау һәм яңадан төзү, шулай ук аларны теркәү

авыл хуҗалыгы терлекләрен тоту, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәк булган җитештерү һәм саклау объектларына алып килә торган юлларны һәм керү юлларын төзү;

авыл хуҗалыгы терлекләрен тоту, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәк булган җитештерү һәм саклау биналарын, урыннарын, өстәмә корылмаларны һәм төзелмәләрне инженер челтәрләренә - электр, су, газ һәм җылылык челтәрләренә, юл инфраструктурасына тоташтыру;

авыл хуҗалыгы хайваннарын сатып алу;

авыл хуҗалыгы техникасын һәм инвентарен, йөк автомобиле транспортын, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү өчен җиһазлар сатып алу;

күпьеллык үсемлекләр утырту өчен орлыклар һәм утырту материалларны сатып алу;

ашлама һәм агулы химикатлар сатып алу.

Чыгымнар планы буенча чыгым эшли башлаучы фермер чараларының һәр исеме (статьясы) буенча түбәндәгечә гамәлгә ашырыла: 90 проценттан да артык булмаганы грант чаралары хисабына һәм 10 проценттан да ким булмаганы эшли башлаучы фермерның җәлеп ителгән чаралары хисабына.

Грант хисабына алынган барлык активлар эшли башлаучы фермерга теркәлергә һәм аның Татарстан Республикасы территориясендәге КФХ белән һәм бры тик эшли башлаучы фермерның КФХ эшчәнлегендә генә кулланылырга тиеш.

КФХ үстерүгә грант максатчан файдаланылмаган очракта грантның максатчан файдаланылмаган суммасы Россия Федерациясе һәм Татрстан Республикасы законнары нигезендә тиешле бюджетларга кайтарылырга тиеш.

Эшли башлаучы фермер тарафыннан грант хисабына алынган мөлкәт грант алган көннән соң 10 ел эчендә Россия Федерациясе законнары нигезендә сатылырга, бүләк ителергә, арендага, башка затларга куллануга бирелергә, алыштырылырга яки пай, кертем рәвешендә кертелергә яки бүтән рәвештә тартып алынырга тиеш тугел. Әлеге шарт эшли башлаучы фермерларга грантлар бирү буенча чараларда катнашучылар өчен мөһим булып тора һәм ул Министрлык белән эшли башлаучы фермер арасында төзелгән килешүләрдә чагылыш табырга тиеш.

КФХ үстерүгә грант КФХ башлыгына бер генә тапкыр бирелә. КФХ башлыгы кече һәм урта эшкуарлыкка булышуга, КФХ үстерүшә һәм башка шундый юнәлештәге Дәүләт программаларының программа чаралары исемлегенә кертелергә мөмкин.

4.4. Көнкүреш кирәк-яраклары белән җиһазландыруга бер тапкыр ярдәм – эшли башлаучы фермерныц Татарстан Республикасы авыл җирлекләре

территориясендә КФХ төзү һәм үстерү максатларында эшли башлаучы фермерның чыгымнар планы буенча исемнәре (статьялары) буенча чыгымнарын бергәләп финанслау өчен кредит оешмасында ачылган счетына Министрлык тарафыннан түбәндәге максатларга күчерелә торган бюджет чаралары:

үз торагыңны сатып алу, төзү һәм ремонтлау, шул исәптән аны сатып алу өчен җәлеп ителгән банк кредитлары (ипотека) буенча төп сумманы һәм процентларын каплау;

бер йөк-пассажир автомобиле сатып алу;

йорт җиһазлары, көнкүреш техникасы предметларын, компьютерлар, элемтә чаралары, электр һәм газ плитәләре, инженер җиһазлары, су чистарту өчен җайланмалар, көнкүрештәге су, җылылык һәм газ җайланмалары, септиклар, су китерү һәм су чыгару җайланмаларын сатып алу һәм алып кайту;

торакны газ һәм электр челтәрләренә, элемтә челтәрләренә, интернетка, су үткәргеченә һәм канализациягә тоташтыру.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшли башлаучы фермерларга көнкүреш кирәк-яраклары белән җиһазландыруга бер тапкыр ярдәмнең иң зур күләмен билгели.

Эшли башлаучы фермерга бирелә торган көнкүреш кирәк-яраклары белән җиһазландыруга бер тапкыр ярдәм суммасы җирле социаль-көнкүреш шартларны, эшли башлаучы фермерның үз акчаларын һәм бизнес-планны исәпкә алып, конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

Эшли башлаучы фермер көнкүреш кирәк-яраклары белән җиһазландыруга бер тапкыр ярдәмне бер генә тапкыр алырга мөмкин.

4.5. Министрлык эшли башлаучы фермерлар тарафынан акчаларның хәрәкәтенә һәм максатчан тотылышына контрольне тәэмин итә.

Акчаларны максатчан тоту өчен җаваплылык эшли башлаучы фермерларга йөкләнә.

4.6. Эшли башлаучы фермер квартал саен Министрлыкка 3-фермер статистик хисаплылыгын һәм КФХ үстерү өчен грант һәм көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итү өчен бер тапкыр ярдәм суммаларын максатчан тоту турында Министрлык билгеләгән форма буенча хисап бирә. КФХ үстерү өчен грант һәм көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итү өчен бер тапкыр ярдәм суммаларын объектларны төзүгә (реконструкцияләүгә) файдаланганда төзелеш тәмамлану факты хакында эшли башлаучы фермер шулай ук 2-КС һәм 3-КС формалары буенча хисап тота.

Бирелә торган хисапларның дөреслеге өчен җаваплылык эшли башлаучы фермерларга йөкләнә.

Бирелә торган хисапларның дөреслеген контрольдә тотуны Министрлык тормышка ашыра.

## 5 бүлек. Программаны гамәлгә ашыру сроклары

Программа 2012–2014 еллар вакыт аралыгында гамәлгә ашырыла.

## 6 бүлек. Программаны гамәлгә ашыруның социаль, икътисадый нәтиҗәләре тасвирламасы

### 6.1. Максатка ирешүдә Программа кертемен гомуми бәяләү

Программа чараларын тормышка ашыру авыл хуҗалыгы өлкәсендә түбәндәге стратегик максатларга ирешүгә ярдәм итәчәк: авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм сату күләмнәрен үстерү һәм аның конкурентлылык сәләтен арттыру, авыл халкының эш белән тәэмин ителешен һәм яшәү дәрәҗәсен үстерү, авыл җирлеге территорияләренең тотрыклы үсеше.

Авыл хуҗалыгы өлкәсендә бурычларны хәл итү дәрәҗәсен чагылдыручы күрсәткечләр булып КФХ хуҗалык итүче субъектлары саны арту, аларда җитештерү күләме үсү һәм эш урыннары саны арту тора.

Программа чараларын гамәлгә ашыру авылда хуҗалык итүнец кече формалары тотрыклы үсү һәм аларга дәүләт ярдәм итү механизмнарын оптимальләштерү өчен алшартлар тудырачак.

### 6.2. Программа чараларын гамәлгә ашыруның социаль һәм икътисадый нәтиҗәләре

Программаның максат күрсәткечләре нигезендә үз хуҗалыкларын төзү һәм үстерү проектларын гамәлгә ашыручы крестьян (фермер) хуҗалыклары саны 329 берәмлек тәшкил итә. Программа чараларын гамәлгә ашыру 990 нан да ким булмаган өстәмә эш урыны булдыруны тәэмин итәчәк.

Нәтиҗәдә дәүләт федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан эшсезлек буенча пособиегә түләүләр күләме кимүдән һәм салым җыемнары артудан өстәмә икътисадый файда алачак.

Программа чараларын гамәлгә ашыру тискәре экологик нәтиҗәләр алып килми, әмма авыл хуҗалыгы җирләре сыйфатын яхшырту буенча культура-техник чаралар юлы белән табигый ресурсларның саклануына ярдәм итәчәк.

Программаның гамәлдә ирешелгән нәтиҗәләре беренчел планлаштырылганнарыннан аерылып торуына тәэсир итә ала торган тышкы шартларга һәм куркынычларга түбәндәгеләр карый:

финанслауның түбән дәрәҗәсе, ул крестьян (фермер) хуҗалыкларының һәм терлекчелек продукциясен беренчел эшкәртү цехларының физик һәм әхлакый искергән техник базасын яцартырга, шулай ук авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр мәйданын киңәйтегә мөмкинлек бирмәячәк;

ягулык-майлау материалларына, авыл хуҗалыгы техникасына һәм җиһазларына, минераль ашламаларга һәм пестицидларга, терлекчелек фермаларын төзү өчен материалларга бәянең инфляция темплары беән аңлатылган күтелә торган үсешеннән артык үсүе.

## 7 бүлек. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү һәм мониторинглау.

Программа чараларын тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү ел саен Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Президенты һәм Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы арасында ел саен төзелә торган килешүдә билгеләнгән нәтиҗәлелек

күрсәткечләренә ирешү дәрәҗәсеннән чыгып, Татарстан Республикасында хуҗалык итүче КФХ саны үсешенең килешүдә билгеләнгән зурлыкларга туры килүе нигезендә гамәлгә ашырыла.

Республикада әлеге Программа кысаларында төзелгән КФХ санын 3219 фермерга арттыру планлаштырыла, алар сайлап алу нигезендә дәүләт ярдәме катнашында үзләренең КФХ үстерү проектларын гамәлгә ашыра алачаклар.

Эшли башлаучы фермерларга грантлар бирү аларны файдалануны мониторинглауны таләп итә. Бу максаттан Министрлык тарафыннан хисаплылык формасы һәм аны тәкъдим итү тәртибе эшләнәчәк һәм расланачак.

Министрлык тәкъдим итә:

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгына Татарстан Республикасы Президенты һәм Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы арасындагы эшли башлаучы фермерларга булышу буенча килешүдә беркетелгән күрсәткеч үтәлүе турында мәгълүматны Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнгән хисаплылык формасы нигезендә;

квартал саен, хисап периодыннан соң килүче айның 25 числосына кадәр Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына – "Озак вакытлы максатчан программаларны эшләү һәм тормышка ашыру тәртибен раслау турында" 20.06.2008 елдагы 412 номерлы карар белән расланган Озак вакытлы максатчан программаларны эшләү һәм тормышка ашыру тәртибенең 5 нче кушымтасында бирелгән форманы тутыру юлы белән максатчан программаларны әзерләү һәм тормышка ашыру турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүматны;

ел саен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына – программаларны тормышка ашыру буенча эшләрнең барышы һәм финанс чараларын куллануның нәтиҗәлелеге турында мәгълүматны билгеләнгән тәртип нигезендә докладлар составында.

## 8 бүлек. Зарур булган ресурсларга ихтыяҗны исәпләү

Программаны финанслау агымдагы елга һәм планлаштырылган периодка федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты турында ел саен кабул ителә торган законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Программа белән каралган барлык чараларны финанслау еллар буенча беркадәр дифференциацияләү белән, аларның кирәклеген һәм нәтиҗәләр вә килә торган елда чараларны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләүне исәпкә алып, Программаны тормышка ашыруның барлык срогы дәвамында гамәлгә ашырыла.

Эшли башлаучы фермерларга КФХ үстерү өчен грантларның, көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә бер тапкыр ярдәмнең гомуми суммасы 2012-2014 елларга 607,546 млн. сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан 320,392 млн. сум.

Программа чараларын финанслау күләмнәре

4 нче таблица
(млн. сум)

| Финанслау чыганаклары | 2012 ел | 2013 ел. | 2014 ел | 2012-2014 еллар. |
|---|---|---|---|---|
| Финанслауның гомуми күләме–барлыгы, шул исәптән: | 155,171 | 221,375 | 231,000 | 607,546 |
| федераль бюджет | 59,193 | 84,53 | 88,20 | 231,923 |
| Татарстан Республикасы бюджеты | 81,872 | 116,72 | 121,80 | 320,392 |
| Җәлеп ителгән акчалар | 14,106 | 20,125 | 21,000 | 55,231 |

## 9 бүлек. Программаны тормышка ашыру белән идарә итү системасы

Программа чараларын тормышка ашыру белән оештыру-методик идарәне Министрлык йөзендә дәүләт заказчысы һәм координатор гамәлгә ашыра.

Министрлык программа чараларын әзерләү һәм тормышка ашыру буенча килештерелгән гамәлләрне тәэмин итә.

Программа чараларын тормышка ашыру мониторингын һәм Программаны тормышка ашыруда катнашучы учреждениеләр вә оешмалар эшчәнлеген һәм аларның Программа чараларын тормышка ашыру буенча килешенгән гамәлләрен координацияләүне Министрлык башкара.

1 нче кушымта

МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА
РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ

МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА
И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# СЕРТИФИКАТ

*Серия НФ-16 № 00 0000*

*Настоящим сертификатом удостоверяется, что*

______________________________________________________________
*(фамилия, имя, отчество)*

*предъявитель паспорта гражданина Российской Федерации*

______________________________________________________________
*(серия и номер, кем и когда выдан)*

______________________________________________________________

*и свидетельства о государственной регистрации крестьянских (фермерских) хозяйств,* ______________________________________________
*(серия, номер и дата, ОГРНИП)*

*является участником программы «Поддержка начинающих фермеров в Республике Татарстан на 2012-2014 годы»,*

*утвержденной приказом Министерства сельского хозяйства и продовольствия Республики Татарстан от ________ 201__ г. № _____ и предоставляется грант на развитие крестьянских (фермерских) хозяйств в размере ________*

*(______________________________________________) рублей.*
*(сумма прописью)*

*единовременная помощь на бытовое обустройство начинающего фермера в размере ________ (__________________________________) рублей.*
*(сумма прописью)*

*Настоящий сертификат выдан на основании приказа Министерства сельского хозяйства и продовольствия Республики Татарстан*

*от ___________ 201__ г. № _____*

*Дата выдачи "___"_____________ 201___ г.*

**Заместитель Премьер-министра**
**Республики Татарстан -**
**министр сельского хозяйства**
**и продовольствия Республики Татарстан** **М.Г.Ахметов**

образец

“2012-2014 елларда Татарстан Республикасында
эшли башлаучы фермерларга булышлык итү”
программасына 2 нче кушымта

# Программаның максаты, бурычы, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм Программа чараларын финанслау

| Максатның исеме | Бурычның исеме | Төп чаралар исеме | Башкаручылар | Чараларны башкару вакыты | Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның билгеләмәләре | | | Финанслау, мең сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 2012 ел | 2013 ел | 2014 ел | 2012 ел | 2013 ел | 2014 ел |
| ТР КФХ стимуллаштыру | КФХ җитештерү базасын киңәйтү һәм модернизацияләү һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару белән шөгыльләнүче гражданнар өчен шартлар тудыру | КФХ үстерүгә грант бирү;<br>эшли башлаучы фермерларны көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә бер тапкыр ярдәм күрсәтү;<br>Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 08.04.2013 елдагы 235 номерлы карары белән расланган “2013-2014 елларда Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлеге базарын җайга салу” дәүләт программасында каралган чараларда катнашу | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | 2012-2014 еллар | Төзелгән КФХ саны, берәмлекләр | 94 | 115 | 120 | 1. Грант<br>барлыгы – 133,4<br>шул исәптән:<br>ТР бюджеты – 70 ,4;<br>федераль бюджет – 50 ,9;<br>җәлеп ителгән чаралар – 12 ,1;<br>2. Ярдәм<br>барлыгы – 21, 7;<br>шул исәптән:<br>ТР бюджеты– 11, 5; федераль бюджет 8, 3;<br>җәлеп ителгән чаралар– 1, 9;<br>Барлыгы – 155,1;<br>шул исәптән:<br>ТР бюджеты – 81, 9; федераль бюджет – 59, 2;<br>җәлеп ителгән чаралар– 14, 1. | 1. Грант<br>барлыгы – 190,3;<br>шул исәптән:<br>ТР бюджеты –98,9; федераль бюджет – 72,3;<br>җәлеп ителгән чаралар – 19,1;<br>2. Ярдәм<br>барлыгы – 31,0;<br>шул исәптән:<br>ТР бюджеты – 16,2;<br>федераль бюджет – 11,7;<br>җәлеп ителгән чаралар – 3,1;<br>Барлыгы – 221,3;<br>шул исәптән:<br>ТР бюджеты – 116,7; федераль бюджет – 84,5;<br>җәлеп ителгән чаралар – 20,1 | 1. Грант<br>барлыгы – 198,6;<br>шул исәптән:<br>ТР бюджеты – 103,2;<br>федераль бюджет – 75,5;<br>җәлеп ителгән чаралар – 19,9;<br>2. Ярдәм<br>барлыгы – 32,4<br>шул исәптән:<br>ТР бюджеты – 11 ;<br>федераль бюджет – 12,3 ;<br>җәлеп ителгән чаралар – 3,3<br>Барлыгы – 231,0;<br>шул исәптән:<br>ТР бюджеты – 121,!; федераль бюджет – 88,1;<br>җәлеп ителгән чаралар – 21,0 |
| | | | | | Өстәмә булдырылаторган эш урыннары саны | 285 | 345 | 360 | | | |

ТР АХһАТМ боерыгына 2 нче кушымта

**Крестьян (фермер) хуҗалыкларын үстерүгә грантлар һәм эшли башлаучы фермерларны көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә бер тапкыр ярдәм бирү турында нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Крестьян (фермер) хуҗалыкларын үстерүгә грантлар һәм эшли башлаучы фермерларны көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә бер тапкыр ярдәм бирү турында әлеге нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) “Эшли башлаучы фермерларга булышу өчен федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлеп бирү кагыйдәләрен раслау турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28 февральдәге 166 номерлы карарын тормышка ашыру хакында” Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2012 елның 22 мартындагы 197 номерлы боерыгы нигезендә һәм “2012-2014 елларга Татарстан Республикасында эшли башлаучы фермерларга булышу” ведомство программасы (алга таба –программа) нигезендә әзерләнгән.

Әлеге Нигезләмәдә кулланылучы төп төшенчәләр

**эшли башлаучы фермер** – әлеге Нигезләмә нигезендә сайлап алу үткән Программа катнашучысы;

**гариза бирүче** – үзен Программа катнашучысы һәм әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән таләпләргә туры килүче итеп тану өчен конкурс комиссичсенә гариза бирүче крестьян (фермер) хуҗалыгы (алга таба – КФХ) башлыгы булган Россия Федерациясе гражданы.

**крестьян (фермер) хуҗалыкларын үстерүгә грант** – эшли башлаучы фермерның чыгымнарын бергәләп финанслау өчен (расланган чыгымнар планы нигезендә) кредит оешмасында ачылган счетына Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан күчерелә торган һәм Программа нигезендә дәүләт булышуының бүтән юнәлешләре кысаларында кайтарылмаган дәүләт ярдәме рәвешендәге акча чаралары (алга таба - грант);

**көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә бер тапкыр ярдәм** –торак һәм көнкүреш шартларын яхшырту максатларында чыгымнар планы нигезендә эшли башлаучы фермерның чыгымнарын бергәләп финанслау өчен расланган кредит оешмасында ачылган счетына Министрлык тарафыннан күчерелә торган дәүләт ярдәме рәвешендәге акча чаралары (алга таба – ярдәм);

**эксперт советы** – КФХ үстерүгә грант һәм көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә бер тапкыр ярдәм бирүгә гаризаларны карап тикшерү өчен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан төзелгән совет;

**чыгымнар планы** –грант һәм (яки) ярдәмне файдалану юнәлешләре чыгымнарының гариза бирүче тарафыннан төзелгән статьялы сметасы (алга таба - Чыгымнар планы).

Нигезләмә грант һәм ярдәм бирү тәртибен, проектларны сайлап алу критерийләрен, максатларны, шартларны, проектларны конкурс сайлап алуын оештыру, үткәрү процедурасын, шулай ук грант һәм ярдәм алучы тарафыннан бирү шартлары бозылган очракта кире кайтару тәртибен билгели.

1.2. Грант һәм ярдәм гаризасын эшли башлаучы фермерларга КФХ үстерүгә грант һәм көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә бер тапкыр ярдәм бирүгә крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу буенча конкурс комиссиясе раслаган фермерга бирелә, аның составы 1 нче кушымта нигезендә раслана.

1.3. Конкурс комиссиясе эшен оештыруны Министрлык башкара.

1.4. Грант һәм ярдәм исемнәре чыгымнар планында күрсәтелгән сатып алына торган мөлкәт, башкарыла торган эшләрнең 10 проценттан да ким булмаган бәясен үз акчалары хисабына түләргә йөкләмә алган эшли башлаучы фермерларга бирелә.

Эшли башлаучы фермер тарафыннан грант хисабына алынган мөлкәт грант алган көннән соң 10 ел эчендә Россия Федерациясе законнары нигезендә сатылырга, бүләк ителергә, арендага, башка затларга куллануга бирелергә, алыштырылырга яки пай, кертем рәвешендә кертелергә яки бүтән рәвештә тартып алынырга тиеш тугел. Әлеге шарт эшли башлаучы фермерларга

1.5. Конкурс комиссиясе карары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм эшли башлаучы фермерларга грантлар һәм ярдәм рәвешендә максатчан бюджет чараларын бирү турында шартнамә төзү өчен нигез булып тора.

**2. Программа катнашучыларына (гариза бирүчеләргә) таләпләр**

2.1. Грантлар рәвешендә максатчан бюджет чараларын алуга хокук эшли башлаучы фермерга – түбәндә күрсәтелгән шартларга туры килүче гариза бирүчегә бирелә:

2.1.1. Гариза бирүче соңгы өч ел эчендә индивидуаль эшкуар эшчәнлеген гамәлгә ашырмаган.

2.1.2. Гариза бирүче элегрәк түбәндәгеләрне алучы булмаган: "Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 2007 елның 24 июлнедәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә крестьян (фермер) хуҗалыгын төзүгә һәм үстерүгә грантны, гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грантны, гариза бирүче башлыгы булып торган крестьян (фермер) хуҗалыгын (алга таба – хуҗалык) теркәгәнгә кадәр алынган эшсез гражданнарның үзмәшгульлегенә булышу өчен түләүләрне, гариза бирүче башлыгы булып торган хуҗалыкны теркәгәнгә кадәр эшкуарлык эшчәнлегенең башлангыч этабын оештыру өчен субсидияләр яки грантлар финанс ярдәме чараларын шулай ук эшли башлаучы фермерларга көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә бер тапкыр ярдәмне.

2.1.3. Гариза бирүче гариза бирү датасына эшчәнлеге авыл җирлекләре территориясендә теркәлү көненнән соң 24 айдан артмаган һәм Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән хуҗалыкның башлыгы булып тора.

2.1.4. Гариза бирүче үзе башлык булып торган хуҗалык урнашкан һәм теркәлгән урын буенча муниципаль берәмлектә даими яши яки даими яшәү урынына күчергә йөкләмә ала һәм әлеге хуҗалык гариза бирүченең бердәнбер эш урыны булып тора.

2.1.5. Гариза бирүченең урта махсус яки югары авыл хуҗалыгы белеме бар, яки авыл хуҗалыгы белгечлекләре буенча өстәмәм профессиональ белем алган, яки авыл хуҗалыгында өч елдан да ким булмаган эш стажы бар, яки өч елдан да ким булмаган вакыт эчендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баруны яки уртак алып баруны гамәлгә ашыра.

2.1.6. Гариза бирүче башлыгы булып торган КФХ "Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 2007 елынң 24 июлендәге 209-ФЗ

номерлы Федераль законда билгеләнгән микропредприятие критериеләренә туры килә.

2.1.7. Гариза бирүченең Программада билгеләнгән эшчәнлек (тармак) юнәлешләре буенча хуҗалыкны төзү һәм үстерү, җитештерелә торган авыл хуҗалыгы продукциясе күләмен арттыру планы була (алга таба – бизне-план).

2.1.8. КФХ хуҗалыгы башлыгы Чыгымнар планында күрсәтелгән сатып алуларның һәрберсенең бәясенең 10 проценттан да ким булмаган өлешен үз акчалары хисабына түләргә йокләмә ала.

2.1.9. КФХ хуҗалыгы башлыгы грант һәм (яки) ярдәмне акчалар аның счетына килгән көннән соң 12 ай эчендә фапйдаланырга һәм грант хисабына сатып алынган милекне бары тик хуҗалыкны үстерүгә генә тотарга йөкләмә ала.

2.1.10.КФХ хуҗалыгы башлыгы өчтән дә ким булмаган өстәмә эш урыны (вакытлыча хезмәткәрләрне, КФХ башлыгыһәм әгъзаларын санамаганда) булдырыга йөкләмә ала.

2.1.11. 30 мең сумнан күберәк суммага авыл хуҗалыгы продукциясе сату турында килешүләр төзегән;

2.1.12.Заявитель обязуется осуществлять деятельность КФХ в течение не менее пяти лет после получения гранта.

2.1.13. Гариза бирүче Россия Федерациясе законнары нигезендә үзенең шәхси мәгълүматларын тапшырырга һәм эшкәртергә ризалык бирә Гариза белән бергә гариза бирүче әлеге пунктта күрсәтелгән шартларга туры килүен раслый торган документлар бирә.

### 3. Программада катнашу өчен конкурс комиссиясенә тапшырыла торган документлар исемлеге

3.1. Прөграммада катнашу өчен гариза бирүче түбәндәге документларны тапшыра:

3.1.1. Әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендә форма буенча гариза;

3.1.2. Әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымта нигезендә форма буенча анкета;

3.1.3. Түбәндә санап кителгән документларның бердән дә ким булмаганын:

а) гариза бирүченең урта-махсус яки югары авыл хуҗалыгы белеме булуын раслый торган белем турында документ күчермәсен;

б) гариза бирүче авыл хуҗалыгы белгечлеге буенча өстәмә профессиональ белем бирү курсларын тәмамлаганлыкны раслый торган документ күчермәсен;

в) гариза бирүченең авыл хуҗалыгында 3 елдан да ким булмаган эш стажы барлыгын раслаучы хезмәт кенәгәсе күчермәсе;

г) өч елдан да ким булмаган вакыт гариза бирүче шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару һәм елына 30 мең сумнан да ким булмаган суммага авыл хуҗалыгы продукциясе сату турында җирле үзидарә органы тарафыннан таныкланган хуҗалык кенәгәсеннән өземтә;

3.1.4. 4 нче кушымта нигезендә форма буенча үз эшеңне оештыру буенча бизнес-план;

3.1.5. Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан гариза биргән көнгә кадәр өч айдан иртәрәк булмаган вакытта алынган өземтә;

3.1.6. КФХ дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе;

3.1.7. Предприятие һәм оешмаларның бердәм дәүләт теркәвендә исәптә тору

турында мәгълүмат хаты күчермәсе (Федераль дәүләт статистика хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль бүлеге хаты ОКВЭД кодлары белән);

3.1.8. Россия Федерациясе гражданы паспорты күчермәсе;

3.1.9. 5 нче кушымта нигезендә форма буенча КФХ үстерүгә грант һәм көнкүреш кирәк-яраклары өчен бер тапкыр ярдәм хисабына бергәләп финанслауга тәкъдим ителә торган чыгымнар планы;

3.1.10.КФХ башлыгының акчалары һәр сатып алу бәясенең 10 процентыннан да ким булмаган күләмдә булуы турында КФХ хисап счетыннан банк өземтәсе;

3.1.11. “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясы таләпләре нигезендә эшли башлаучы фермерның микропредприятие үлчәмнәренә туры килүен раслый торган эшчеләрнең уртача саны турында белешмә;

3.1.12. 30 мең сумнан артык суммага авыл хуҗалыгы продукциясен сату турында беренчел килешү;

3.1.12. Гариза бирүченең һәм аның гаиләсе әгъзаларының милкендә (куллануында) КФХ урнашу һәм теркәлү урыны буенча бердәнбер торагы булуны (булмауны) раслаучы Техник инвентаризация бюросыннан яки Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Территориаль Идарәсеннән документлар;

3.1.13. Проект эшләренә лицензиясе булган оешма тарафыннан төзелгән локаль-смета хисабы һәм объект схемасы теркәлгән (грантны төзелешкә яки реконструцияләүгә кулланганда) җыелма-смета хисабы;

3.1.14. Салым органыннан салымнар һәм барлык дәрәҗәдәге бюджетларга һәм бюджеттан тыш фондларга бүтән мәҗбүри түләүләр буенча түләү вакыты чыккан бурычлары юклыгын раслый торган белешмә;

3.1.15. Эш белән тәэмин итү территориаль үзәгеннән эшсез гражданнарның эшкуарлык эшчәнлеге рәвешендә үзмәшгульлеген оештыру өчен дәүләт ярдәме күрсәтү факты булмау турында белешмә, күрсәтелгән дәүләт ярдәменең чыгым статьясы исемен күрсәтеп;

3.1.16. 6 нчы кушымта нигезендә форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;

3.2. Белешмәләрнең дөреслеге һәм бирелгән документларның чын булуы өчен җаваплылык гариза бирүчегә йөкләнә.

3.3. Нигезләмәнең 3 бүлегендәге 3.1. пунктында күрсәтелгән документлар (документларның күчермәләре) КФХ башлыгы тарафыннан имзаланырга, КФХ башлыгы мөһере белән расланылырга тиеш.

3.4. Нигезләмәнең 3 бүлегендәге 3.1. пунктында күрсәтелгән гариза составына кертелүче документлар тегелергә, номер сугылырга һәм КФХ мөһере сугылырга тиеш.

3.5. Нигезләмәнең 3 бүлегендәге 3.1 пунктында күрсәтелгән документлар Конкурс сайлавын үткәрү турында хәбәр итү кәгазендә (белдерүдә) күрсәтелгән срокларда һәм адрес буенча тапшырыла. Документлар тапшыру өчен билгеләнгән срокны бозу аларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

3.6. Гаризаларны әзерләү һәм тапшыру белән бәйле барлык чыгымнарны гариза бирүчеләр каплый.

3.7. Нигезләмәнең 3 бүлегенең 3.1. пунктында күрсәтелгән документлар 7 нче кушымта нигезендә документлар исемлеге белән бергә биреләләр. Исемлек

конвертка салынмый. Документларны кабул иткәндә исемлеккә, кабул итү датасын күрсәтеп, документлар кабул ителүне раслаучы тамга куела. Исемлекнең кабул итү турында тамга белән булган бер нөсхәсе гариза бирүчедә, икенчесе конкурс комиссиясендә кала.

Әгәр гариза бирүче конкурс комиссиясе карарына тәэсир итә дип саный икән, ул өстәмә рәвештә фермер хуҗалыгын программаның потенңиаль катнашучысы буларак сыйфатлаучы теләсә нинди документлар тапшыра ала, мондыйларны:

а) тәкъдим итә торган хатлар;

б) җир кишәрлегенә милек хокукын дәүләт теркәвенә алу турында белешмә күсчермәсен һәм (яки) билгеләнгән тәртиптә теркәлгән җир кишәрлеген арендалау (озак вакытлы) шартнамәсе;

в) әлеге Нигезләмәнең 8 нче кушымтасы нигезендә эшли башлаучы фермерның техникасы, терлеге һәм кошлары булуы турында җирле үзидарә органыннан алынган белешмә;

г) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларга милек хокукын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе;

д) техник чара паспорты күчермәсен (КФХ башлыгы милкендә техник чарабулганда);

е) торак пунктыннан КФХ җитештерү объектларына кадәр ераклыкны күрсәтеп, җирле үзидарә органыннан белешмә;

ж) объектлар фотосурәтләре һәм башка документлар.

3.2.6. Грант һәм ярдәм эшли башлаучы фермерларга Конкурс комиссиясе карары буенча, эшли башлаучы фермерларга максатчан бюджет чараларын бирү турында килешү буенча комиссия беркетмәсе нигезендә Министрлык боерыгы белән 9 нчы кушымта нигезендә форма буенча бирелә.

3.2.7. Грант һәм ярдәм бирү федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслау лимитларын исәптә тотып гамәлгә ашырыла.

3.2.8. Эшли башлаучы фермер счетына күчерелгән КФХ үстреүгә һәм көнкүреш кирә-яраклары белән тәэмин итүгә грант һәм ярдәм ел дәвамында акча түләнми торган хисаплар юлы белән тотыла.

## 4. Гаризаларны кабул итү һәм карап тикшерү

4.1. Извещение Грантлар һәм ярдәм бирү буенча конкурс сайлап алуында катнашуга гаризалар кабул итү башлану турында хәбәр Министрлыкның http://agro.tatarstan.ru/ рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникаңия челтәрендә урнаштырыла. Сайлап алуда катнашу өчен гаризалар конкурс сайлап алуы турында хәбәрдә күрсәтелгән адрес буенча биреләләр. Хәбәрдә конкурсны үткәрү урыны һәм вакыты, элемтә телефоны, документлар бирү тәртибе һәм конкурс шартлары турында мәгълүмат алырга, норматив документлар белән танышырга мөмкин булган Министрлык сайты бүлеге күрсәтелә.

4.2. Гаризаларны кабул итү башлану вакыты – хәбәр басылып чыккан көннән соң килә торган көн. Гариза бирүчеләрдән гаризаларны кабул итү тәмамлану срогы – гаризалар кабул итү башланганнан көннән соң 20 (егерме) календарь көне.

4.3.Гариза бирүчеләр конкурс комиссиясенә әлеге Нигезләмәнең 3 бүлеге таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән гаризаларны бирәләр. Гариза кәгазьдә

конвертка салынган документлар белән бирелә. Конверт конкурс комиссиясе сәркатибе тәкъдим ителә торган документларны теркәлгән исемлек белән чагыштырып чыкканнан соң ябыштырыла һәм КФХ мөһере белән раслана. Конвертта программаның исеме, проектның исеме, КФХ исеме, гариза бирүченең фамилиясе, исеме, әтисе исеме һәм адресы күрсәтелә.

4.4. Комиссяи сәркатие:

4.4.1. гаризалар кабул итү тәмамланган моменттан соң өч эш көне эчендә документлар белән гаризалар исемлеген рәсмиләштерә һәм аларны Эксперт советы каравына карап тикшерү һәм грантлар вә ярдәм бирү мөмкинлеге турында конкурс комиссиясенә тәкъдимнәр әзерләү өчен тапшыра;

Карар кабул иткәндә Эксперт советы түбәндәге критерияләр белән җитәкчелек итә:

әлеге Нигезләмә белән каралган документлар барлыгын тикшерә;

гариза бирүченең һәм ул тәкъдим иткән документларның Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә;

конкурс комиссиясе карап тикшерүе өчен проект чыгару өчен баллар санын исәпли.

4.5. Эксперт советы тарафынан гаризалар кабул ителгән моменттан соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча конкурс Комиссиясенә грант һәм ярдәм бирү мөмкинлеге турында тәкъдимнәр белән яисә аларны бирүгә баш тарту турында бәяләмә кертелә һәм юллана.

4.6. Гаризаларны карап тикшерү йомгаклары Эксперт советы бәяләмәсе белән рәсмиләштерелә. Эксперт советы бәяләмәсе мәҗбүри рәвештә грант һәм ярдәм бирү мөмкинлеге яисә аларны бирүдән баш тарту, баш тартуның сәбәбен күрсәтеп, турында киңәшләрне үз эченә ала. Эксперт советы бәяләмәсе “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Министрлыкның http://agro.tatarstan.ru/ рәсми сайтында Планнар һәм программалар, конкурслар бүлегендә урнаштырыла.

4.7. Эксперт советы бәяләмәсен алган моменттан соң 5 эш көннән дә соңга калмыйча Конкурс комиссиясе утырышы үткәрелә, аның нәтиҗәләре буенча эшли башлаучы фермерларга грант һәм ярдәм бирү яисә бирүдән баш тарту турында карар кабул ителә, ул Конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. .

4.8. Әлеге Нигезләмә нигезендә карап тикшерелгән гариза гариза бирүчегә кире кайтарылмый һәм Программаны тормышка ашыру барышында Министрлыкта саклана.

4.9. Грантны һәм ярдәмне бирү тәртибе һәм документлар формалары турында мәгълүмат “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникаңия челтәрендә, Министрлыкның http://agro.tatarstan.ru/ рәсми сайтында урнаштырыла.

## 5. Конкурс сайлап алуын үткәрү

5.1. Конкурс комиссиясе утырышы Эксперт Советы беркетмәсе алынган моменттан соң 3эш көненнән дә соңга калмыйча, гариза бирүчеләрне кара-каршы сөйләшү өчен чакырып үткәрелә.

5.2. Программада катнашуга гариза бирүче түбәндәге очракта конкурс комиссиясе белән кире кагыла:

5.2.1. Нигезләмәнең 2 бүлегендә күрсәтелгән грант һәм ярдәм бирү шартларына гариза бирүченең туры килмәве;

5.2.2. гариза бирүче тарафыннан дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр һәм документлар бирү;

5.2.3. гариза бирүченең салым һәм бүтән мәҗбүри түләүләр буенча, шулай ук өстәп исәпләнгән, әмма барлык дәрәҗәдәге бюджетларга һәм бюджеттан тыш фондларга түләнмәгән штрафлар һәм пенялар буенча вакыты чыккан бурычлары булу;

5.2.4. гариза бирүченең грант һәм ярдәмнең чыгымнар планы буенча һәр статьясын каплар өчен сумманың 10 проценттан да ким булмаган өлешен каплау өчен җәлеп ителгән чаралары булмау.

5.3. Гариза бирүчеләр тәкъдим иткән документларны бәяләү өчен Конкурс комиссиясе килеп туган сорауларга кирәкле аңлатмалар бирү өчен экспертларны һәм башка белгечләрне чакырырга хокуклы.

5.4. Конкурс комиссиясе конкурс сайлап алуы җиңүчеләрен кара-каршы сөйләшү һәм гариза бирүчеләрнең тәкъдим иткән документларын бердәм анализлау нигезендә, түбәндәге критерияләрне кулланып билгели:

**Бизнес-планда күздә тоту:**

I. Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгының өстенлекле юнәлешләрен:

а) ит, сөт терлекчелеге, атчылык -10 балл;

б) яшелчәчелек (ачык һәм ябык грунтта) - 9 балл;

в) бөртекле һәм бөртекле-кузаклы культуралар үстерү - 9 балл;

г) җимеш һәм җиләк культуралары үстерү - 8 балл;

д) авыл хуҗалыгы кошчылыгы - 7 балл;

е) бәрәңгечелек - 5 балл;

ж) дуңгызчылык - 5 балл;

з) сарыкчылык һәм кәҗә үрчетү - 5 балл;

к) балчылык - 2 балл;

II. Җирле халык очен эш урыннары булдыру, проектның бизнес-планыбелән каралган:

а) 3 эш урыны: - 3 балл;

б) 4 - 8 эш урыны: - 7 балл;

в) 8 - 15 эш урыны: - 10 балл;

III. Хезмәт хакы дәрәҗәсе:

а) 1,0 дән 1,5 кадәр МРОТ - 5 балл;

б) 1,5 тән күбрәк МРОТ - 10 балл;

IV. Авыл хуҗалыгында эш стажы булу:

а) 3 - ел - 5 балл;

б) 3-елдан артык - 10 балл;

V. Милкендә һәм (яки) куллану хокукында авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлеге булу:

а) 5,0 га кадәр -5 балл;

б) 5,1 га.дан 50 га кадәр - 7 балл;

в) 50 га.дан артык - 10 балл;

VI. КФХ җитештерү объектларының торак пункттан ераклыгы:

а) 1 км - 5 балл;

б) 1 км артык - 10 балл;

VII. Милкендә авыл хуҗалыгы техникасы булу:

а) 1 берәмлек - 5 балл;

б) 2 һәм күбрәк - 10 балл;

VIII. Профессиональ белеме булу:

а) урта-махсус авыл хуҗалыгы - 5 балл;

б) югары авыл хуҗалыгы - 10 балл;

IX. Сорала торган дәүләт ярдәме суммасы:

а) иң зур күләмнән 10 % ка әзерәк- 5 балл;

б) иң зур күләмнән 10% тан азрәк - 10 балл;

X. Җирле үзидарә органнарыннан, физик затлардан, җәмәгатьчелек оешмаларыннан тәкъдим итү хатлары булу:

а) бер - 5 балл;

б) ике һәм күберәк -10 балл.

Иң күп мөмкин булган балл саны - 100. Проектны Конкурс комиссиясе каравына чыгару өчен 43 балл җыярга кирәк.

5.5. Конкурс комиссиясе карары конкурс комиссиясе составының 2/3 өлеше булганда гади күпчелек тавыш белән кабул ителә, конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе (алга таба – беркетмә) белән рәсмиләштерелә, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

конкурс комиссиясенең составы;

тавыш бирү нәтиҗәләре;

Конкурс сайлап алуы җиңүчеләре исеме;

һәр эшли башлаучы фермерга эшчәнлек юнәлешләрендә дәүләт ярдәме суммасы.

5.6. Беркетмә конкурс комиссиясе рәисе һәм сәркатибе тарафыннан имзалана. Беркетмәгә конкурс комиссиясе әгъзаларының тавыш бирү кәгазе теркәлә.

5.6.1. Беркетмә имзаланган көннән соң биш көн эчендә Министрлык Конкурс сайлап алуы нәтиҗәләрен раслау турында боерык чыгара;

5 көн эчендә Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының районнардагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә мәгълүматны конкурста катнашучыларга җиткерү өчен конкурс комиссиясе кабул иткән карар турында язма хәбәр юнәлдерә.

5 көн эчендә конкурс сайлап алуы катнашучылары һәм җиңүчеләре турында мәгълүматны Министрлыкның http://agro.tatarstan.ru/ рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыра.

## 6. Грантны һәм ярдәмне күчерү һәм кире кайтару тәртибе

6.1. Гаризалары конкурс сайлап алуында җиңгән эшли башлаучы фермерлар (алга таба – грант алучылар) конкурс сайлап алуы нәтиҗәләре турында хәбәр алган көннән соң 5 эш көне эчендә Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыралар:

а) Министрлык боерыгы белән расланган формада грант һәм (яки) ярдәм күләме турында хисап;

б) конкурс комиссиясе тарафыннан расланган юнәлешләр аралыгында чыгымнар планы;

в) Министрлык боерыгы белән расланган формада грант алучы анкетасы;

г) 8 нче кушымтага яраклы рәвештә КФХ үстерүгә грант һәм көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә бер тапкыр ярдәм бирү турында килешү.

6.2. Конкурс комиссиясе сәркатибе грант һәм ярдәм бирүгә тәкъдим ителгән документларны аларның килү тәртибендә махсус журналга терки, аңа номер сугылырга, тегелергә, Министрлык мөһере белән расланырга тиеш. Теркәү язмасы үз эченә теркәү номерын һәм документларны кабул итү датасын алырга тиеш.

6.3. Документларны теркәү датасыннан соң 5 эш коне эчендә Министрлык кергән документларны тикшерә һәм грант һәм ярдәм күләме турында хисапларны һәм грант алучылар тарафыннан Нигезләмәнең 6.1. пункты нигезендә тәкъдим ителгән килешүләрне имзалый.

6.4. Грант алучыга грант бирүдән баш тарталар:

әгәр Нигезләмәнең 6.1. пунктында каралган документлар пакеты тулы булмаса;

Нигезләмәнең 6.1. пункты нигезендә бирелгән документларда күрсәтелгән белешмәләр, хисапларның гамәлдәге белешмәләр, хисапларга туры килмәве билгеле булса.

6.5. Грантны һәм (яки) ярдәмне эшли башлаучы фермерлар тарафыннан кредит учреждениеләрендә ачылган хисап счетларына күчерү өчен Министрлык Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгының Казначылык департаментына түбәндәгеләрне юллый:

6.5.1. Конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсен раслау турында Министрлык боерыгын;

6.5.2. һәр эшли башлаучы фермер буенча:

грант һәм (яки) ярдәм күләменең Нигезләмәнең 6.1. пунктындагы “а” һә “г” пунктчаларында күрсәтелгән хисабын һәм Нигезләмәнең 6.3. пункты нигезендә имзаланган грант бирү турында килешү күчермәсен.

6.6. Грант һәм ярдәм акчаларын максатчан файдалануны контрольдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6.7. Грант һәм ярдәмне максатчан файдаланмау һәм (яки) аларны алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар бирү фактлары билгеле булганда, грант һәм (яки) ярдәмнең бирелгән суммасы законнар нигезендә тиешле ТР һәм РФ бюджетларына кире кайтарылырга тиеш.

6.8. Кире кайтару Министрлык тикшерүе акты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Грант һәм (яки) ярдәмне кире кайтару турында таләпләр билгеләнгән вакытта үтәлмәгән очракта кире кайтарту Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә башкарыла.

17.07.12 № 121/2-пр.
ТР АХҺАТМ боерыгы белән расланган
Ниезләмәгә 1 нче кушымта

КФХ үстерүгә грантлар һәм эшли башлаучы фермерларны көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә бер тапкыр ярдәм күрсәтү өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу буенча Ведомствоара конкурс комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Әхмәтов Марат Готыф улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары - авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры, Конкурс комиссиясе рәисе |
| Якушкин Николай Михайлович | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары, Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары |
| Җигһаншина Әнисә Азат кызы | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының Предприятиеләрнең структурасын үзгәртү һәм агробизнесны үстерү бүлеге 1 разрядлы белгече |
| Байтимеров Камияр Миҗаһит улы | Татарстан фермерлары һәм крестьян хуҗалыклары ассоциациясе рәисе |
| Гарифуллина Фәридә Галимҗан кызы | Агросәнәгать комплексы хезмәткәрләре һөнәри берлеге Татарстан республика оешмасы рәисе |
| Молокин Александр Николаевич | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Предприятиеләрнең структурасын үзгәртү һәм агробизнесны үстерү бүлеге җитәкчесе, |
| Баскаков Николай Викторович | “Россельхозбанк” ААҖ Татарстан төбәк филиалының директор урынбасары (килешү буенча) |
| Гобәйдуллина Фәйрүзә Газиз кызы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Предприятиеләрнең структурасын үзгәртү һәм агробизнесны үстерү бүлеге әйдәүче киңәшчесе |
| Угаров Алексей Владимирович | Инвестицияләр үсеше агентлыгының эшкуарлыкны үстерү идарәсе җитәкчесе |

| | |
|---|---|
| | (килешү буенча) |
| Зиннәтуллин Ришат Рифкат улы | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Инфраструктура үсеше идарәсе инфраструктура үсеше бүлеге җитәкчесе (килешү буенча) |
| Мөхәмәтгалиев Фәрит Нургали улы | Казан дәүләт аграр университетының икътисад һәм менеджмент институты директоры (килешү буенча) |
| Хафизова Элеонора Борисовна | Агробизнес кадрларын яңадан әзерләү Татарстан институтының укыту-методик эш буенча проректоры (килешү буенча) |
| Галлиев Рәшит Якуп улы | Лаеш муниципаль районының “Таң” крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы (килешү буенча) |
| Мөбәрәкҗанов Илнур Фәрит улы | Саба муниципаль районының “Умырзая” җитештерүче-сатучы авыл хуҗалыгы җитештерүе кооперативы рәисе (килешү буенча) |
| Котдусов Гәбделәхмәт Гәбтеләхәт улы | Биектау муниципаль районы крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы (килешү буенча)” |

17.07.12 № 121/2-пр.
ТР АХҺАТМ боерыгы белән расланган
Нигезләмәгә 2 нче кушымта

КФХ үстерүгә грант һәм эшли башлаучы фермерны көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә бер тапкыр ярдәм бирү өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу буенча ведомствоара конкурс комиссиясенә
комиссия рәисенә - ТР Премьер-министры урынбасары – ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры
М.Г.Әхмәтовка
_____________________________________________
_____________________________________________
адресы буенча яшәүче_______________________

“2012-2014 елларда Татарстан Республикасында эшли башлаучы фермерларга булышлык итү” программасы буенча сайлап алуы конкурсында катнашуга

**ГАРИЗА**

_______________________________________________________________________
*(гариза бирүченең Ф.И.Ә.)*

_______________________________________________________________________
*(гариза бирүченең тулы рәсми атамасы)*

“2012-2014 елларда Татарстан Республикасында эшли башлаучы фермерларга булышлык итү” программасы буенча сайлап алуы конкурсында катнашучылар составна мине кертүегезне сорыйм. Катнашу һәм программады катнашучыларны сайлап алу шартлары белән таныш булуымны һәм килешүемне раслыйм.

Шуның белән түбәндәгеләрне раслыйм:

кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә грант, шул исәптән КФХ үстерүгә грант, гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грант, эшсез гражданнарны үзмәшгульлегенә булышуга түләүләр, көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә бер тапкыр ярдәм алмадым;

соңгы өч ел эчендә индивидуаль эшкуар сыйфатында эшкуарлык эшчәнлеге алып бармадым.

2. Бирелә торган документларда яки аларның күчермәләрендә китерелгән барлык мәгълүмат чын булып тора һәм грант бирүгә документларны карап тикшерүдә катнашучы затларның алары белән танышуына каршы килмим.

Грантны һәм (яки) эшли башлаучы фермерны көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә бер тапкыр ярдәмне алган моменттан соң грант һәм (яки) эшли башлаучы фермерны көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә бер тапкыр ярдәм хисабына минем тарафтан алынган мөлкәтне 10 ел дәвамында сатмаска, бүләк итмәскә, арендага, башка затларга куллануга бирмәскә, алыштырмаска, пай, кертем рәвешендә кертмәскә, Россия Федерациясе законнары нигезендә башка рәвештә бирмәскә гарантия бирәм.

______________________________ «____» _________________201_ ел.
(фамилиясе, исеме,әтисе исеме) (гаризаны бирү датасмы)

________________________________
(гариза бирүче имзасы, мөһере)

17.07.14 № 121/2-нд
ТР АХһАТМ боерыгы белән расланган
Нигезләмәгә 3 нче кушымта

Катнашучы анкетасы (Мәгълүмат кәгазе)

| № | Күрсәткеч исеме | Гариза бирүче мәгълүматлары |
|---|---|---|
| 1. | КФХ тулы исеме, Ф.И.Ә.и. | |
| 2. | ИНН | |
| 3. | ОГРИП (ОГРН) | |
| 4. | ОКВЭД буенча эшчәнлек төре | |
| 5. | Туу датасы | |
| 6. | Гамәлдәге адресы (эшчәнлекне чынбарлыкта гамәлгә ашыру урыны) | |
| 7. | Юридик адресы (тору урыны) | |
| 8. | Хәрби хезмәткә мөнәсәбәте:<br>а) хәрби йөкләмәле (хәрби билет №________)<br>б) хәрби йөкләмәле түгел | |
| 9. | КФХ дәүләт теркәвенә алу көне һәм урыны | |
| 10. | Авыл хуҗалыгында эшләү стажы | |
| 11. | Грант алганга кадәр КФХ әгъзалары һәм хезмәткәрләре, язарга: барлыгы, шул исәптән<br>а) кфх башлыгы,<br>б) кфх әгъзалары,<br>в) җәлеп ителүче хезмәткәрләр | |
| 12. | Грант алганга кадәр КФХ активлары суммасы (милек белән идарә итү) | |
| | җир кишәрлеге (га), (хокукын күрсәтергә) | |
| | - күчемсез милек (торак булмаган бина) | |
| | күчемсез милек (торак урыны, КФХ урнашу урыны буенча торак булу-булмау) | |
| | - транспорт чаралары,<br>- авыл хуҗалыгы хайваннары,<br>- җиһазлар | |
| 13. | Уртача айлык<br>-керем (хезмәт хакы;кертемнәр буенча %; дивидендлар, аренда түләвеннән һәм башкалар | |
| | -чыгым (кредит, заем, салымнар, арендалау түләүләре) | |
| 14. | Тәрбиясендә булган затлар саны | |

Җитәкче

имза МУ (имзаны аңлату)

17.07.14 № 121/2-кл
ТР АХhАТМ боерыгы белән расланган
Нигезләмәгә 4 нче кушымта

**Бизнес-планның тәкъдим ителә торган формасы**

Титул бите

## 1. 1.Резюме (проект турында кыскачы мәгълүмат)

Крестьян (фермер) хуҗалыгы турында топ мәгълүмат:

КФХның тулы исеме:

Гмәлдәге адресы:

Элемтә телефоны:

К(Ф)Х башлыгының кыскача резюмесы:

Фамилиясе, исеме, әтисе исеме:

Туу датасы:

Белеме:

Паспорт мәгълүматлары:

К(Ф)Х эшкуарлык эшчәнлегенең топ төре:

## 2. Проект тасвирламасы:

Проектның максаты;

Эшчәнлек алып бару территориясе ;

Проектның социаль – икътисадый әһәмияте;

Бина, җир кишәрлеге мәйданы;

Арендалау, аена 1 кв. метр өчен аренда бәясе.

Җитештерелә торган продукция, эшләр, хезмәт күрсәтүләр ассортименты (1 таб.)

1 таблица

| т/б № | Исеме |
|---|---|
| | |
| | |

Төп кулланучылар;

Салым түләү системасы төре.

## 3. Проектның финанс структурасы

2 нче таблица

**Чыгымнар планы (бер тапкыр чыгымнар)**

мең сум.

| т/б № | Товар, күрсәтелә торган хезмәт, башкарыла торган эшләр исеме | Саны | Берәмлек очен бәясе | Гомуми бәясе | Хисабына бәясен түләү (финанслау чыганаклары) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Грант (яки бер тапкыр бирелә | Үз чаралары | Заем чаралары |
| 1 | 2 | | | 3 | 4 | 5 | 6 |
| I. Крестьян (фермер) хуҗалыгын төзү һәм үстерү белән бәйле чыгымнар | | | | | | | |
| 1. | | | | | | | |
| ... | | | | | | | |
| | 1бүлек буенча | | | | | | |
| II. Крестьян (фермер) хуҗалыгын көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә бәйле чыгымнар | | | | | | | |
| 1. | | | | | | | |
| • •• | | | | | | | |
| | II бүлек буенча | | | | | | |
| | Чыгымнар планы буенча барысы | | | | | | |

3 таблица

**Тотылганнар (прөектны гамәлгә ашыру вакытында еллар буенча)**

| т/б № | Исеме | Суммасы, сумнарда | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2012 | 2013 | 2014 | 2015 | 2016 |
| | Чимал (запас өлешләр, азыклар h.б.) | | | | | |
| | Коммуналь түләүләр:<br>-электр энергиясе<br>-су белән тәэмин итү<br>-җылылык энергиясе<br>-газлаштыру<br>-канализация | | | | | |
| | Хезмәт хакы | | | | | |
| | Даими эш урыннары саны, данә | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Арендалау | | | | | |
| | Салым күчерүләр | | | | | |
| | Пенсия Фондына күчерүләр | | | | | |
| | Бүтән чыгымнар | | | | | |
| | Барысы: | | | | | |

4 нче таблица

Җитештерү һәм гамәлгә ашыру планы (проектның һәр елына)

Үсемлекчелек

| т/б “ | Продукция исеме | Мәйдан, гектар | Уңышлылык, центнер/га | Тулаем җыем, тонна | Товар продукциясе күләме | Бәясе, мең сум/ тонна | Мең сумны гамәлгә ашырудан |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | | | |
| 2. | | | | | | | |
| 3. | | | | | | | |
| 4. | | | | | | | |
| 5. | | | | | | | |
| | Барысы: | | | | | | |

5 нче таблица

Терлекчелек (проектның һәр елына)

| т/б № | Продукңия исеме | Терлек башы, баш | Савым/артым, кило | Тулаем продукция | Товар продукциясе күләме | Бәясе, мең сум/ тонна | Мең сумны гамәлгә ашырудан керем |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | | | |
| 2. | | | | | | | |
| 3. | | | | | | | |
| | Барысы: | | | | | | |

Әгәр эшли башлаучы фермер хезмәтләр күрсәтергә яки нинди булса да эшләр башкарырга планлаштыра икән, аларны гамәлгә ашырудан керемне исәпләүне 4,5 таблицаларга туры клә торган рәвештә башкарырга кирәк.

6 нчы таблица

**Эшчәнлек юнәлешләре буенча гамәлгә ашырудан керем (проектны гамәлгә ашыру вакытында еллар буенча)**

| Исеме | Суммасы | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 201 | 201 | 201 | 201 | 201 |
| | | | | | |
| | | | | | |
| Барысы: | | | | | |

7 нче таблица

**Проектны гамәлгә ашыру вакытында эшкуарлык эшчәнлегенең төп финанс-икътисадый күрсәткечләре динамикасы**

| т/б № | Исеме | Суммасы, сум |
|---|---|---|
| 1. | Грант суммасы | |
| 2. | Үз чаралары | |
| 3. | Заем чаралары | |
| 4. | Проект көченә чыкканга кадәр гамәлгә ашырудан булган керем | |
| 5. | Проект көченә чыкканнан соң гамәлгә ашырудан булган керем | |
| 6. | Төп кирәк-яракларны сатып алуга чыгымнар | |
| 7. | Җитештерүгә һәм гамәлгә ашыруга тотылганнар | |
| 8. | Чыгымнар барысы | |
| 9. | Керем | |
| 10. | Рентабельлелек | |

ИЭ - Крестьян (фермер)
хуҗалыгы башлыгы Имза, мөһер

Ф.И.Ә.и.

17.07.14 № 121/2-ил.
ТР АХһАТМ боерыгы белән расланган
Нигезләмәгә 5 нче кушымта

РАСЛЫЙМ:
____________________/___________/
Конкурс комиссиясе рәисе
____ __________ 201_ ел

**Грант һәм ярдәмнән файдалану юнәлешләренең чыгымнары планы:**

| т/б № | Грант һәм ярдәмнән файдалану юнәлешләрене | Саны (берәмлек, гектар, данә) | Бәясе (сум) | Гомуми сумма (сум) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Барлыгы | шул исәптән | | |
| | | | | | грант | Ярдәм | Үз чаралары |
| I | КФХ төзүгә һәм үстерүгә грант | | | | | х | |
| 1 | Авыл хуҗалгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлеге сатып алу | | | | | | |
| 2 | Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәк булган җитештерү һәм саклау биналарын төзү өчен проект документларын эшләү (шифрны ачырга) | | | | | | |
| 3 | Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәк булган җитештерү һәм саклау биналарын, урыннарын, өстәмә корылмаларны, инженер челтәрләрен, киртәләрне һәм төзелмәләрне сатып алу, төзү, ремонтлау һәм яңадан төзү, шулай ук аларны теркәү (шифрны ачырга) | | | | | | |
| 4 | Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәк булган җитештерү һәм саклау объектларына алып килә торган юлларны һәм керү юлларын төзү (шифрны ачырга) | | | | | | |
| 5 | Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәк булган җитештерү һәм саклау биналарын, урыннарын, өстәмә корылмаларны һәм төзелмәләрне инженер челтәрләренә - электр, су, газ һәм җылылык челтәрләренә, юл | | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | инфраструктурасына тоташтыру (шифрны ачырга) | | | | | | |
| 6 | Авыл хуҗалыгы хайваннарын сатып алу (шифрны ачырга) | | | | | | |
